СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ 27.09.2017

КАРАР 40-164

с. Набережные Моркваши

Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 елдан № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пунктында, Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 11 пунктында «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» , Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының 2017 елның 18 сентябрендәге 39-161 номерлы карары, «Җирле референдумны уздыру инициативасы турында» Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 18 сентябрендәге 19 номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2017 елның 19 ноябренә Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

"2018елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчалар юллау белән килешәсезме:

- Никольский, Пятидворка, Лесные Моркваши, Покровка авылларында урамнарны яктырту буенча чаралар үткәрү;

- Яр буе Морквашы, Покровка авылларында халыкның тормыш куркынычсызлыгы һәм милкен саклау чараларын тәэмин итү (видеокүзәтү камералары урнаштыру, янгын гидрантлары урнаштыру, янгынга каршы резервуарларны урнаштыру һәм ремонтлау);

-Пустые Моркваши бистәсендә мәктәп маршруты буенча тукталыш павильоны төзелеше;

- Десятидворка ав. суэтем башнясын һәм павильонын ремонтлау;

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х.Гаязов